РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

№ 77 **2017 елның 15 ноябре**

***Постановление*** ***Карар***

«2018 елга һәм 2019-2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «2018 елга һәм 2019-2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне 2017 елның 30 ноябренә 14-00 сәгатькә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының конференц-залында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт.

2. Карала торган проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча язмача җибәрелә дип билгеләргә: Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт, 19 нчы каб., 5-43-70 факсы буенча яисә электрон почта адресына – chistay@tatar.ru ачык тыңлаулар көненә кадәр. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр эш көннәрендә 8-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр кабул ителә (төшке аш 12-00 сәгатьтән 13-00 сәгатькә кадәр).

3. Йөкләргә:

- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы аппараты һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

күрсәтелгән карар проекты буенча ачык тыңлаулар, тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының финанс-бюджет палатасы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль район Советының Бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясе карар проектын гавами тыңлауларда әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып эшләп бетерергә һәм фикер алышу барышында кергән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы утырышына проектны кертергә.

4. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «2018 елга һәм 2019-2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» карар проектын билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары Р.Г. Хаматовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов